ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Кама Тамагы
муниципаль районы
***Иске Барыш***
***авыл җирлеге***
**Башкарма**
**комитеты**

422835, Иске Барыш авылы, Үзәк урамы, 15
тел.(884377)30-3-18, ИНН / КПП 1622004570 / 162201001
ОКПО 93064659 ОГРН 1061672003436

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Исполнительный**
**комитет**
***Старобарышевского***
***сельского поселения***
Камско-Устьинского
муниципального района

422835, с. Старое Барышево, ул.Центральная, 15
тел.(884377)30-3-18, ИНН/КПП 1622004570 / 162201001
ОКПО 93064659 ОГРН 1061672003436

---

**“4” сентябрь 2018 ел** **№ 6**

**КАРАР**

**Җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

2002 нче елның 12 нче июнендәге 67-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” гы Федераль законның 15 нче маддәсе, 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 22,56 нче маддәләре, 2004 нче елның 24 нче мартындагы 23-ТРЗ номерлы “Җирле референдум турында”гы Татарстан Республикасы Законының 17 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге Уставының 15 нче маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР КЫЛА**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Барыш авыл җирлеге территориясендә түбәндәге мәсъәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге территориясендә турыдан-туры яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән, (биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр, беренче төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларыннан кала) җирлек территориясендә тавыш бирү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсъәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны

җибәрү хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2019 нчы елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме:

*** Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;**
*** Җирлек торак пунктлары чикләрендә территорияләрне төзекләндерүне оештыру;**
*** Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, су бүлүне җирлекләр чикләрендә оештыру:**

**ӘЙЕ ЮК"**

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:
- ТР, Кама Тамагы районы, Иске Барыш авылы, Үзәк урамы, 15 нче йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Кыртапа авылы, Мәктәп урамы, 10 нчы йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтэренең рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районы**
**Иске Барыш авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе И.Р.Җиһаншин**